ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е

К А Р А Р

2019 елның «01» октябре

№1388

"Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 12 декабрендәге 1882 номерлы карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәгн № 210-ФЗ Федераль закон, «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 1999 елның 27 июнендәге 151-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 12 декабрендәге 1882 номерлы карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.4 пунктның 6нчы абзацын төшереп калдырырга;

2.6 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының техник регламентларның һәм проект документларының (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 348 һәм 39 өлешләре нигезендә кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган проект документларының таләпләренә туры килүе турында Дәүләт төзелешен күзәтү органы бәяләмәсе (Дәүләт төзелешен күзәтүне гамәлгә ашыру күздә тотылган очракта);»;

3.4.1 пунктындагы 4 пунктчасында «Проект документлары» сүзләреннән соң (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3_8 һәм 39 өлешләре нигезендә кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган проект документациясен да кертеп)»сүзләрен өстәргә.

2.Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетында бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, гражданнар өчен уңайлы булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга

3.Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче Н.Р. Залаков

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72